**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

«26» 12 2025 ел Яр Чаллы № 4472

«2024-2026 елларга Тукай муниципаль районы халкы арасында сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру, физик культура һәм спортны үстерү» Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 1 февралендәге 312 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Тукай муниципаль районы халкы арасында 2024-2026 елларга сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру, физик культура һәм спортны үстерү» программасын финанслау суммасы арту сәбәпле, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 елның 4 декабрендәге 2827-р номерлы карары нигезендә

**КАРАР БИРӘ:**

1. Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 1 февралендәге 312 номерлы карары белән расланган «2024-2026 елларга Тукай муниципаль районы халкы арасында сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру, физик культура һәм спортны үстерү» программасына 2024 елга Тукай муниципаль районы «Спорт мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесен финанслау күләмен Татарстан Республикасы «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджетына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү хисабына 106775,20 сум күләмендә арттырып үзгәрешләр кертергә.
2. «2024-2026 елларга Тукай муниципаль районы халкы арасында сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру, физик культура һәм спортны үстерү» программасы паспортының «Программаны еллар һәм финанслау чыганаклары буенча бүлеп финанслау күләмнәре» бүлеген яңа редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| Объемы финансирования программы с распределением по годам и источникам финансирования | 2024-2026 елларда ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 7 484 485,20 сум тәшкил итә, шул исәптән:<br>2024 елда – 2 473 280,0 сум;<br>2025 елда – 2 755 205,20 сум; |

| | |
|---|---|
| | 2026 елда – 2 256 000 сум.<br>Программаны финанслау күләмнәре фаразлау характерында һәм тиешле елга һәм план чорына бюджет проектын формалаштырганда ел саен төгәлләштерелергә тиеш.<br>Республика, федераль бюджет акчалары һәм бюджеттан тыш чыганаклар ел саен төзелә торган шартнамәләр һәм килешүләр нигезендә билгеләнәчәк. |

3. «2024-2026 елларга Тукай муниципаль районы халкы арасында сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру, физик культура һәм спортны үстерү» программасын гамәлгә ашыру буенча чаралар» кушымтасында «Район территориясендә физик культураны, массакүләм спортны үстерү өчен шартлар тәэмин итүгә бәйле чаралар, рәсми физкультура-савыктыру һәм спорт чараларын үткәрүне оештыру (Аутсорсинг)» 20 пунктында 2025 елга Тукай муниципаль районы «Спорт мәктәбе» өстәмә белем бирү учреждениесенә кушымта нигезендә 106775,20 сум финанс средстволары өстәргә.

4. Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлегенә әлеге карарны 3 эш көне дәвамында районның рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштыруны тәэмин итәргә.

5. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе Л.Н. Маняпов

Тукай муниципаль районы Ба
комитетының 2025 елның __
26.12, 4472 номерлы карарына
кушымта

**«2024-2026 елларга Тукай муниципаль районы халкы арасында сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру, физик культура һәм спортны үстерү» программасын гамәлгә ашыру буенча чаралар**

| № | Чаралар исеме | Финанс чараларын бүлү, еллар буенча (сумнарда) | | | Финанслау чыганагы | Башкаручы |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2024 ел | 2025 ел | 2026 ел | | |
| 20. | Район территориясендә физик культураны, массакүләм спортны үстерү өчен шартлар тәэмин итүгә бәйле чаралар, рәсми физкультура-савыктыру һәм спорт чараларын үткәрүне оештыру (аутсорсинг) | 100000,00 | 100000,00 | 100000,00 | Җирле бюджет | Тукай муниципаль районы «Спорт мәктәбе» ӨББ МБУ |
| | | 287688,96 | 106775,20 | | Республика бюджеты | Тукай муниципаль районы «Спорт мәктәбе» ӨББ МБУ |